Исполнительный комитет
Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального
района Республики Татарстан
423655 Менделеевский район
с.Тихоново ул. Шишкина д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл жирлеге
башкарма комитеты
423655 Менделеевск районы Тихоново авылы
Шишкин урамы 3а

тел./факс 8 (85549) 3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

16.03. 2023 ел № 1

КАРАР

Хөкем ителүчеләрнең
мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендә
җәза үтәү урыннарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 49 һәм 50 статьялары, Россия Федерациясе Җинаять-башкарма кодексының 25 һәм 39 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты мәҗбүри эшләр һәм төзәтү эшләре рәвешендәге җинаять җәзасын үтәүне тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәзаны үтәү өчен урыннар исемлеген 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге территориясендә хөкем ителүчеләрне төзәтү эшләре рәвешендә җәза үтәү урыннары исемлеген 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http//pravo.tatarstan.ru бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.М. Карманов

Килештерелде

"Татарстан Республикасы буенча җәзаларны
үтәү федераль хезмәте идарәсе
җинаять-башкарма инспекциясе"
Федераль казна учреждениесенең
Менделеевск муниципальара
филиалы башлыгы И.Г.Сәләхов

Килештерелде
"Татарстан Республикасы буенча
җәзаларны үтәү федераль хезмәте
идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе"
Федераль казна учреждениесенең
Менделеевск муниципальара филиалы
башлыгы
_______________ел

И.Г. Сәлахов

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2023 елның __________
карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге территориясендә
мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәзаны үтәү өчен
урыннар исемлеге

| № п/п | Оешманың исеме | Адресы | Эш төрләре |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге башкарма комитеты | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авылы Шишкин ур., 3а й. | Территорияне җыештыру, очраклы чүп-чар җыю, кар җыю, кар өемнәре, чүп-чарны төяү һәм бушату, су скважинасында һәм биологик чистарту корылмаларында ремонт эшләре, йорт яны территорияләрен һәм урман утырту полосалары юлларын төзекләндерү, җир эшләре. |